**СОВЕТ НАРМОНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422630 с.Нармонка,
Ул.Молодежная, д. 12 А
тел.8-(84378)4-62-24
факс: 8-(84378)4-62-24

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НАРМОНКА АВЫЛ ВДРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422630 Нармонка авылы,
Яшьлэр урамы, 12 а нчы йорт,
тел.8-(84378)4-62-24
факс: 8-(84378)4-62-24

**2022елның «9» ноябре** **152 номер**

**КАРАР**

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Нармонка авыл җирлеге советының 2018 елның 11 апрелендәге 100 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларына түбәндәге үзгәрешләр кертү турында**

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларына, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренә, рәис урынбасарларына, аудиторларына, муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 13 декабрендәге 1222 номерлы карары нигезендә, Нармонка авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. **«**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Нармонка авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнар формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 11 апрелендәге 100 номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Нармонка авыл җирлеге советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

**7 пункт**. Муниципаль хезмәткәргә түләнә өлешен түбәндәге эчтәлекле 10 пунктча белән тулыландырырга:

**“норматив булмаган хезмәт көне шартларында вазыйфаи окладның 2 процентыннан артмаган күләмдә эшләгән өчен айлык компенсация түләве.»**

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә)

. 4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Нармонка**
**авыл җирлеге Советы рәисе** **А.О.Солягин**